


# *КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР*

**№4 2023 ел**

***98 нче татар – рус урта гомуми белем бирү мәктәбе***

**Дуслар! Менә безнең бусагада – Яңа 2024 нче ел. Без 2023 нче елда бәхетле дә, уңышлы да, үкенечле дә, шатлыклы һәм югалтулы да булып үткән елларны искә төшерәбез. Һәрбер елны үзенә хас үзенчәлекләре белән истә тотачакбыз. Яңа елда шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын! Бәрәкәтле еллар сезгә! Һәрберебезгә тынычлык, мәхәббәт, иминлек, бәхет, шатлык, сәламәтлек, күңел тынычлыгы һәм уңышлар телим! Тормыштан ямь-тәм табып һәм кадерле булып яшәргә насыйп булсын! Яңа ел белән, кадерле дусларым!**



## Кыш

Менә  түземсезлек белән көтеп алган кыш та килеп җитте. Бөтен җир ап-ак карга күмелде.  Тирә-якта кар җем-җем итеп ялтырый. Агачлар да җылы мамык шәлләрен ябынды. Елга һәм күлләр боз белән капланды. Көннәр кыскарды, төннәр озынайды. Ә без дусларым белән чанада, чаңгыда, тимераякта шуабыз, шугалакта хоккей уйныйбыз. Саф һавада йөрү- күңелгә рәхәтлек бирә. Урамда салкын. Җылы итеп киенеп йөрергә кирәк. Кыш үзенең нинди ел фасылы икәнен сиздерә. Зәмһәрир суыклары белән безнең күңелгә үтеп керә. Ә шулай да кыш  минем иң яраткан ел фасылларымның берсе.

**7А сыйныф укучысы Нәҗипова Әминә**



## Яңа ел бәйрәме

Яңа ел- минем яраткан бәйрәмем. Ул иң гаҗәп, мавыктыргыч һәм көтелгән бәйрәмнәрнең берсе. Яңа ел бәйрәме алдыннан  миңа  йортны һәм чыршыны бизәү бик ошый. Бу бәйрәм атналыгында, гадәттә, узган елны анализлыйм, нинди хаталар ясаганмын, нинди фәннәрдән белемем җитеп бетмәвен тагын бер тапкыр кузаллап чыгам. Яңа елга мин чиста һәм яңа уйлар белән керергә тырышам. Ә Яңа ел бәйрәме көнне тәмле ризыклар пешереп, өстәлне мул итеп әзерләү дә минем яраткан шөгыльләремнең берсе  булып тора.  Яңа елда барлык кешеләргә дә  сәламәтлек, күңел тынычлыгы, уңышлар, бәхет теләп калам. Барлык кешеләргә дә бәрәкәтле тормыш телим!

**11А сыйныфы укучысы Хайруллина Рената**

2023 нче ел Рәсәйдә **Педагог һәм остаз елы** дип игълан ителгән иде. Бу ел бик уңышлы гына үтеп китеп бара.Укытучыларыбызны зурлап бик күп кенә чаралар үткәрелде, аларның эшләре зурлап бәяләнде. Фидакарь хезмәтләре өчен бик күп кенә укытучыларыбыз медаль, грамота, диплом һәм рәхмәт хатлары белән бүләкләнделәр. Ә киләсе 2024 нче елны Рәсәй президенты Владимир Владимирович Путин **Гаилә елы** дип игълан итте. Карар гаиләне яклау һәм традицион кыйммәтләрне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен популярлаштыру өчен кабул ителде, - диде Владимир Владимирович Путин.



Киләсе 2024 нче ел астрология буенча Аждаһа елы. Кытай астрологиясендә Аждаһа “Ян” елы булып санала, ул ирләр энергисе белән бәйле, димәк. Бу вакыт — ныкышмалылык һәм гамәлләр кылу вакыты. “Инь” еллары, киресенчә, хатын-кызлар энергиясе белән бәйле һәм пассиврак санала. Шуңа алдагы елда кыю кешеләргә уңыш елмаерга тиеш! Аждаһа Көнчыгыш белән бәйле. Ә ул яңа башлангычлар юнәлеше булып санала. Шуңа Аждаһаның башын еш кына чыгып килгән кояшка каратып сурәтлиләр. Алдагы елда яңа эшләр башлаудан курыкмагыз!Аждаһа елында туган кешеләр — үз-үзләренә ышанучан, аларга табигатьтән җитәкчелек итү һәм башкаларны илһамландыру сәләте бирелгән. Агач һәм яшел төс белән берлектә ул һәркемгә бәяләп бетергесез ярдәмче була ала. Тотынырга озак кына куркып торган эшләргә алдагы елда курыкмыйча тотынсагыз була. Мөгаен, киләсе елда тауларны да күчереп булыр. Мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз!

Астрологлар билгеләвенчә, 2024 ел кайберәүләр өчен аеруча уңышлы булачак. Алар – Күсе, Әтәч, Маймыл елында туган кешеләр. Шулай ук Аждаһа елында туганнар өчен дә яхшы көннәр килә. 2024 елда бу кешеләр уңышлы хезмәттәшлек итүгә ирешер, үзләрендә намуслылык һәм шәфкатьлелек артуын тояр. Ә менә Үгез, Эт, Елан елында туганнар бераз сак

булсын, алар өчен карьера, финанс өлкәсендә һәм шәхси тормышта катлаулылыклар килеп чыгарга мөмкин. Яшел агач Аждаһа елы кешеләр тормышының барлык өлкәләренә йогынты ясаячак, үзгәрешләр китерәчәк. Парлылар тормышында ел буе романтика һәм тигез мәхәббәт хөкем сөрер.

Аждаһа – горур зат. Бу сыйфат әлеге елда шәхси тормышын җайларга теләүчеләрдә чагылыш табачак. Үпкәчелләр парларын читләштерергә мөмкин. Үпкәләрне онытырга теләүчеләргә, сабырларга Аждаһа мәрхәмәтле булачак. Аждаһа елында күп балалар тууы көтелә! Моңа Аждаһаның “утлы” темпераменты сәбәпче булачак. 2024 ел лидерлык һәм ораторлык сәләтләренә ия булганнар өчен уңышлы булачак, дип фаразлый белгечләр. Ләкин казанышларга ирешер өчен икейөзлелек, явызлык кебек сыйфатларны якын да китермәскә кирәк булачак. Киң күңелле, юмарт, шәфкатьле кешеләрнең барлык ниятләре тормышка ашарга тиеш.

Әйе, Яңа ел бәйрәме ишек какканда, безнең Аждаһа елында туган хөрмәтле укытучыларыбызга да без берничә сорау белән мөрәҗәгать итәргә булдык. Кемнәр соң алар?

**Ахмерова Насима Рафиковна, Касыймова Гөлнур Наиловна, Каюмова Диана Фердинандовна, Иванова Вера Андреевна, Халилова Гульнара Адхамовна- нәкъ менә Аждаһа елында туучы укытучыларыбыз!**

**-Хөрмәтле Насима Рафиковна! Сез тумышыгыз белән кайсы яклардан? Гаиләдә ничә бала үстегез? Әти-әниләрегез нинди һөнәр ияләре?**

- Мин тумышым белән Оренбург якларыннан. Без гаиләдә ике бала үстек: абыем һәм мин. Әти белән әни безнең өчен үрнәк иделәр. Әтием озак еллар колхоз бригадиры булып эшләде. Эшенә карата да, безгә карата да бик таләпчән һәм гадел кеше булды. Әнием балалар бакчасы мөдире булып эшләде. Йомшак күңелле булуына карамастан, үз эшен җиренә җиткереп башкарды.

- **Насима Рафиковна, сез нинди югары уку йортын тәмамладыгыз?**

- Мин Уфа дәүләт университетының психология факультетын тәмамладым.

- **Укытучы һөнәренә теләкне кем уятты?**

- Укытучы булам дигән хыялым башлангыч сыйныфта укыганда ук башланды. Беренче укытучым Клара Абдрахмановнаның безне ничек укытуы, безгә карата бик итагатьле булуы- мине шушы һөнәрне сайлауга төп теләкне уятты.

**-Киләсе ел-сезнең ел, ягъни Аждаһа елы. Сез бу елдан нәрсә өмет итәсез? Коллегаларга 2024 нче елда нинди теләкләр теләр идегез?**

-2024 нче ел якынлашып килә. 2023 нче ел минем өчен бик сынаулы ел булды. Авырлыкларга карамастан, яхшы вакыйгаларга да бик бай булды. Ләкин мин ышанам, барысы да әйбәт булыр, минем өметләрем акланыр! Бусагада 2024 нче ел! Без бәхет һәм үкенеч, шатлык һәм югалту булган елны озатабыз. Яңа елда шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын!!!

**-Хөрмәтле Гөлнур Наиловна! Сез тумышыгыз белән кайсы яклардан? Гаиләдә ничә бала үстегез? Әти-әниләрегез нинди һөнәр ияләре?**

- Тумышым белән мин Яшел Үзән районы Олы Күлбаш авылыннан. Гаиләдә без өч бала: апам Гөлнар, мин һәм энем Илнур. Әтием-Гыйльметдинов Наил Гыйльметдин улы 18 ел мәктәптә физик тәрбия дәресләрен алып барды. Авылда депутат булды. Аннан авылда авыл советы идарәчесе булып эшләде. Ә әнием- Гыйльметдинова Нурания Сәләх кызы 38 ел мәктәптә математика укытучысы булып эшләде. Шуның 18 елын директор урынбасары, ә 12 елын директор вазифасын башкарды.

- **Гөлнур Наиловна, сез нинди югары уку йортын тәмамладыгыз?**

- Мин Казан дәүләт педагогика университетының татар теле, әдәбияты һәм Татарстан тарихы дигән бүлекне тәмамладым. Шулай ук музыка хезмәткәре дигән кенәгәм дә бар.

- **Укытучы һөнәренә теләкне кем уятты?**

- Укытучы һөнәренә теләк миңа әти-әниемнән күчкәндер дип уйлыйм. Аларның укучы балаларга ничек белем бирүләрен, өйдә дәфтәр тикшерүләрен, ничек итеп укыту планнарын язуларын, укучы балалар белән нинди мөгаләмәдә булуларын күреп үстем. Кечкенәдән энем белән "Укытучы-укытучы" уйный идек. Шулай ук әниемнең шигырьләр иҗат итүе, мәкаләләр язуы һәм аны район гәҗитендә бастырылуы, әтиемнең өздереп гармунда уйнавы, матур итеп җырлавы -минем татар теле һәм әдәбияты укытучы булуыма төп этәргеч булгандыр дип уйлыйм.

**-Киләсе ел-сезнең ел, ягъни Аждаһа елы. Сез бу елдан нәрсә өмет итәсез? Коллегаларга 2024 нче елда нинди теләкләр теләр идегез?**

-Әйе, 2024 нче -минем ел. Мин бу елдан бары тик изге гамәлләр, якты киләчәк көтәм. Дөньялар тынычлансын иде. Һәркемгә бәрәкәтле озын гомерләр, саулык-сәламәтлек, күңел тынычлыгы, зурдан-зур уңышлар, шатлык-куанычлар телим!!!

**-Хөрмәтле Диана Фердинандовна! Сез тумышыгыз белән кайсы яклардан? Гаиләдә ничә бала үстегез? Әти-әниләрегез нинди һөнәр ияләре?**

-Мин тумышым белән Казан шәһәреннән. Гаиләдә ике бала үстек. Әнием-инглиз теле укытучысы. Ә этием-очучы.

**-Диана Фердинандовна, сез нинди югары уку йортын тәмамладыгыз?**

-Мин КГПУ ны тәмамладым.

**- Укытучы һөнәренә теләкне кем уятты?**

-Укытучы һөнәренә теләкне гаиләм уятты.

**-Киләсе ел-сезнең ел, ягъни Аждаһа елы. Сез бу елдан нәрсә өмет итәсез? Коллегаларга 2024 нче елда нинди теләкләр теләр идегез?**

-Минем теләгем-тизрәк сугыш бетсен иде. Дөньяда һәрчак аяз күк йөзе булсын!Улымның магистратураны уңышлы гына тәмамлавын телим. Ә коллегаларыма һөнәри һәм иҗади эшләрендә уңышлар теләп калам!!!

**-Хөрмәтле Вера Андреевна! Сез тумышыгыз белән кайсы яклардан? Гаиләдә ничә бала үстегез?**

-Мин тумышым белән Бөгелмә шәһәреннән. Гаиләдә бер бала.

**-Вера Андреевна, сез нинди югары уку йортын тәмамладыгыз?**

-Мин Казан Федераль Университетын тәмамладым. Белгечлегем- тарих укытучысы.

- **Укытучы һөнәренә теләкне кем уятты?**

-Укытучы һөнәренә теләкне миндә мәктәптә укыганда тарих укытучым уятты. Ул миндә тарих фәненә карата кызыксыну һәм мәхәббәт барлыкка китерде. Тарих укытучым минем күңелемә идеал укытучы булып кереп урнашты.

**-Киләсе ел-сезнең ел, ягъни Аждаһа елы. Сез бу елдан нәрсә өмет итәсез? Коллегаларга 2024 нче елда нинди теләкләр теләр идегез?**

-Киләсе Яңа елда мин укытучы карьерасын үстерергә телим. Ә коллегаларыма иксез-чиксез сабырлык һәм ныклы сәламәтлек телим!

**Хөрмәтле Гөлнара Адхамовна! Сез тумышыгыз белән кайсы яклардан? Гаиләдә ничә бала үстегез?**

-Мин тумышым белән Питрәч районыннан. Гаиләдә ике бала.

**-Гөлнара Адхамовна, сез нинди югары уку йортын тәмамладыгыз?**

-Мин КФУ ИФМК ны тәмамладым.

- **Укытучы һөнәренә теләкне кем уятты?**

-Укытучы һөнәренә теләкне миндә инглиз теле укытучым уятты.

**-Киләсе ел-сезнең ел, ягъни Аждаһа елы. Сез бу елдан нәрсә өмет итәсез? Коллегаларга 2024 нче елда нинди теләкләр теләр идегез?**

-Киләсе елда мин Карелияга ял итәргә барырга телим. Ә коллегаларыма сәламәтлек һәм гаилә иминлеге теләп калам!!!

Хуш киләсең, Яңа ел!
Табыныбыз мул булсын,
Якыннарым, дус-ишләрем,
Табын түрендә торсын!
Яңа ел барыбызга
Китерсен бәхет, шатлык.
Сәламәтлек юлдаш булсын,
Кирәкми башка затлык!
Эшләребез уң булсын,
Тик шатлыклы минутлардан
Безнең гомерләр торсын!
Яңа ел котлы булсын!

**Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Сезгә берничә киңәш биреп китәбез.**

Яңа ел чыршысын ничек дөрес бизәргә, нинди бизәкләр сайларга? Барлык кешеләрнең иң яраткан һәм көтелгән бәйрәме алдыннан без Аждаһа елын ничек каршы алырга, нәрсә кияргә һәм үз киемебез өчен нинди төсләр сайларга кирәклеген сөйләргә булдык.

«Яңа ел киеме» бер төсле булырга яки берничә төсне берләштерергә мөмкин. Шуны онытмагыз — төсләр бәйрәмнең кәефе һәм гомуми атмосферасын гына түгел, ә сезгә Аждаһа елын нәрсә китерәчәгенә дә бәйле.

1. **Теләсә нинди төсмердәге яшел төс -** Яңа ел киеме өчен төп төс булып калачак. Ул төрле стильләр өчен яраклы гына түгел, ә нечкә, якты да була ала. Бу — гармония, чәчәк ату һәм яңарту төсе. 2024 елда яшел төс аеруча актуаль булачак, чөнки бу киләсе елның яклаучысы төсе.

2. **Шәмәхә:** көндәлек киемдә бик сирәк очрый һәм шуңа күрә теләсә нинди образга аерым нәфислек өсти. Көнчыгышта бу төс патшалык һәм рухилык белән ассоциацияләнә һәм еш кына дини церемонияләрдә күренә.

3. **Алсу төс** шулай ук зирәклек һәм интуиция төсе булып санала. Аны еш кына яңа елда рухи сыйфатларын үстерергә теләүчеләр сайлый. Алсу төснең йөзегезгә, чәчләрегезгә туры килгән төсмерләрен сайлау бик мөһим.

4. Аждаһалар ялтыравыкны яраталар, шуңа күрә **алтын төстәге кием сайлагыз**! Бу төс байлык һәм люкс символы һәм иң мөһим очраклар өчен дә яраклы. Мифлар буенча, аждаһалар барлык ялтыравыклы һәм кыйммәтле әйберләрне ярата, шуңа күрә киемдәге алтын төс сезгә киләсе 2024 нче елда бәхет китерәчәк. Яңа ел сезгә, бәхет, шатлык, җан тынычлыгы алып килсен!




**Редколлегия:**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Әмирхан Еники, 23.**
**Тел: 8 (843) 236-24-12**

**Сездән язмалар көтеп калабыз!**